**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Иске Ильдеряк җирлеге башлыгы**

КАРАР

№ 1 09.06.2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә, Аксубай муниципаль районының Иске Ильдеряк авыл җирлеге Уставына таянып, **КАРАР БИРӘМ**:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгының 11.06.2015 елның 2 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен (кушымта) расларга.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ильдеряк авыл җирлеге Советы бинасындагы мәгълүмат стендында халыкка хәбәр итәргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгы: В.К. Альметкин

Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгы 09.06.2020 елның, № 1 карарына кушымта

### Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе

Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп терминнар кулланыла:

1) граждан мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә җибәрелгән, тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;

2) тәкъдим - гражданның законнарны һәм башка норматив хокукый актларны, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыять эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм башка өлкәләрен яхшырту буенча рекомендациясе;

3) гариза - гражданинның аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яисә башка затларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү турындагы үтенече, йә законнар һәм башка норматив хокукый актлар бозылу, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар эшендәге җитешсезлекләр турында хәбәр итү, йә күрсәтелгән органнар һәм вазыйфаи затларның эшчәнлеген тәнкыйтьләү;

4) шикаять - гражданинның бозылган хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен йә башка затларның хокукларын, ирекләрен яисә законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау турында үтенече;

5) вазыйфаи зат - хакимият вәкиле функцияләрен даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләт белән гамәлгә ашыручы йә дәүләт органында яисә җирле үзидарә органында оештыру-боеру, административ-хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге Советына һәм Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, җәмәгать фикерен һәм гражданнарның актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм

методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорга гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (алга таба - вазыйфаи зат) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау чоры елга ике тапкыр тәшкил итә: ярты ел һәм узган ел өчен.

6. Һәр яртыеллык нәтиҗәләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы зат гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә.

7. Җаваплы зат гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерүне гамәлгә ашыра һәм күрсәтелгән анализ нәтиҗәләре буенча хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр аналитик белешмә төзи һәм аны урнаштыру өчен җибәрә.

8. Анализ үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, каралган мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрне дә кертеп;
- мөрәҗәгатьләр структурасы һәм тематикасы;
- шәхси кабул итү өчен җаваплы затларның шәхси кабул итүендә кабул ителгән гражданнар саны;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булганда).

9. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә гомумиләштерелгән анализ Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында елга ике тапкыр урнаштырыла (http://aksubaevo.tatarstan.ru).